| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**14.11.2017 ел** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2860** |

2017 елның III кварталына «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге буенча торак урындагы 1 кв.метр гомуми мәйданның уртача базар бәясен раслау турында

Россия Федерациясе Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының 2017 елның икенче яртыеллыгына бәясе нормативы һәм 2017 елның III кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынының гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2017 елның 27 июнендәге 925/пр номерлы боерыгы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Яшь гаиләләр өчен социаль түләүләр исәпләү өчен 2017 елның III кварталына «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге буенча торак урындагы бер квадрат метр гомуми мәйданының бәясе нормативын федераль бюджет акчалары хисабына торак биналар сатып алуга (төзүгә) бирелә торган күрсәтелгән социаль түләүләр күләмен 36 207 (утыз алты мең ике йөз җиде) сум күләмендә расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин